СОВЕТ ЛЕБЯЖИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ ЛЕБЯЖЬЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

21.09.2018 с. Лебяжье № 100

**Татарстан Республикасы**
**Алексеевск муниципаль районының**
**Лебяжье авыл җирлеге составына**
**керүче торак пунктларда**
**гражданнар җыенына әзерләнү һәм аны үткәрү**
**тәртибе турында"гы Нигезләмәне раслау хакында**

"Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында"гы 6 октябрь, 2003 ел, 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1 нче маддәсе, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында"гы 28 июль, 2004 ел, 45-ЗРТ санлы Татарстан Республикасы законының 35 нче маддәсе һәм **Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Лебяжье авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставының 23 нче маддәсен гамәлгә ашыру максатында**

**Лебяжье авыл җирлеге Советы карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Лебяжье авыл җирлеге торак пунктларында гражданнарның җыенына әзерләнү һәм аны үткәрү тәртибе турында"гы Нигезләмәне кушымта нигезендә расларга.
2. Әлеге карарны Лебяжье авыл җирлегенең рәсми сайтында, хокукый мәгълүмат порталында, шулай ук Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Лебяжье авыл җирлеге Советы бинасында мәгълүмат стендына урнаштырырга.
3. Әлеге карар аны рәсми бастырып чыгарган вакыттан үз көченә керәчәк.
4. Әлеге карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземдә калдырам

**Алексеевск муниципаль районының**
**Лебяжье авыл җирлеге башлыгы,**
**Совет рәисе** **М.Б.Зверев**

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районының
Лебяжье авыл җирлеге
Советы карарына кушымта
21.09.2018 № 100

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Лебяжье авыл җирлеге торак пунктларында гражданнарның җыенына әзерләнү һәм аны үткәрү тәртибе турында Нигезләмә**

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Лебяжье авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнарның җыенына әзерләнү һәм аны үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмә "Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында"гы 6 октябрь, 2003 ел, 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1 нче маддәсе, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында"гы 28 июль, 2004 ел, 45-ЗРТ санлы Татарстан Республикасы законының 35 нче маддәсе һәм Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Лебяжье авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставының 23 нче маддәсен нигезендә эшләнде.

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1. Гражданнар җыены гомуми, тигез һәм халыкның турыдан-туры ихтыярын белдерүе нигезендә үткәрелә.

1.2. Гражданнар җыенында торак пункт территориясендә даими яки күбесенчә яшәүче, яшәү урыны буенча әлеге торак пунктта теркәлгән кешеләр катнашырга хокуклы.

1.3. Гражданнар җыенында катнашу ирекле.

1.4. Гражданнар җыенда үзләре катнашалар һәм аларның һәркайсы бер тавышка ия.

1.5 Гражданнар җыены турыдан-туры халыкның җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүе максатында үткәрелә.

## Гражданнар җыенының вәкаләтләре

1.6. Гражданнар җыены түбәндәге мәсьәләләр буенча үткәрелергә мөмкин:

күрсәтелгән торак пункт керә торган, күрсәтелгән торак пункт территориясен башка җирлек (муниципаль район) территориясенә кертелергә тиешле торак пунктта җирлек (муниципаль район) чикләрен үзгәртү мәсьәләсе буенча;

җирлекнең чикләрне үзгәртү, күрсәтелгән җирлекне үзгәртеп кору вәкаләтле органы вәкаләтләре гражданнар җыены тарафыннан гамәлгә ашырыла;

җирлекнең вәкаләтле органы вәкаләтләре гражданнар җыены тарафыннан тормышка ашырыла торган җирлектә, әгәр сайлау хокукына ия җирлек кешеләренең саны 100 дән артык булса, җирлекнең вәкаләтле

органын булдыру, анның саны һәм вәкаләтләр срогы турындагы мәсьәлә буенча;

жирлекнең вәкаләтле органы вәкаләтләре гражданнар жыены тарафыннан тормышка ашырыла торган жирлектә гражданнарның үзара салым акчасын кертү һәм файдалану мәсьәләсе буенча;

жирлек составына керә торган яки муниципаль район чикләрендә авыллар арасындагы территориядә урнашкан торак пунктта әлеге торак пункт территориясендә гражданнарның үзара салым акчасын кертү һәм файдалану мәсьәләсе буенча;

авыллар арасындагы территориядә урнашкан торак пунктта халыкның инициативасын күрсәтү максатында жирле үзидарәне оештыру һәм гамәлгә ашыру белән бәйләнгән мәсьәләләр буенча;

халык тыгыз урнашмаган яки барырга кыен булган урыннарда урнашкан жирлектә халык саны кимендә 100 кеше тәшкил итсә, жирлекне бетерү мәсьәләсе буенча;

авыл торак пунктында авыл торак пункты старостасы кандидатурасын күрсәтү, шулай ук авыл торак пункты старостасы вәкаләтләрен срогыннан элек туктату мәсьәләләре буенча;

авыл торак пунктында гражданнар жыены шулай ук муниципаль хезмәт вазыйфасына муниципаль хезмәт турындагы Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда конкурс үткәргәндә конкурс комиссиясе составына кандидатуралар күрсәтү максатында үткәрелергә мөмкин.

**Гражданнар жыенын матди һәм оештыру ягыннан тәэмин итү**

1.7. Жыенны жирлек башлыгы үткәрә.

1.8. Жыенга әзерләнү һәм аны үткәрү белән бәйләнгән чыгымнар жирлек бюджеты акчасы хисабына сарыф ителә.

## 2. Гражданнар жыенын чакыру тәртибе

Гражданнар жыенын үткәрү инициативасы

2.1. Торак пунктта гражданнар жыенын үткәрүдә инициативаны

- жирлек башлыгы;
- кимендә ун кешедән торган сайлау хокукына ия, гражданнар жыенында катнашырга хокукы булган (ягъни Россия Федерациясенең торак пункт территориясендә даими яки күбесенчә яшәүче, яшәү урыны буенча әлеге торак пунктта теркәлгән, 18 яшькә житкән эшкә сәләтле гражданнар) кешеләр төркеме, шулай ук торак пункт территориясендә даими яки күбесенчә яшәүче һәм жирле үзидарәне тормышка ашырганда Россия Федерациясе һәм федераль законнарның халыкара килешүләре нигезендә хокукларга ия булучы чит ил гражданнары.

2.2. Торак пункт кешеләренең инициативасы имзалар кәгазе (1 нче кушымта) яки инициатив төркем жыелышы беркетмәсе рәвешендә теркәлә, анда түбәндәге мәсьәләләр күрсәтелеп, гражданнар жыены үткәрү инициативасын күрсәтү турында карар кабул ителә:

гражданнар жыенына чыгарыла торган мәсьәләләр;

гражданнар жыенын үткәрү сроклары;

гражданнар жыенын чакыру турындагы инициативаны хуплаучы һәр гражданның фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган көне, паспорты яки

аны алмаштыручы документының сериясе һәм номеры, яшәү урынындагы адресы, имзасы яки имза куелган дата.

2.3.Җыен үткәрү инициативасын яклап җыелырга тиешле имзалар саны сайлау хокукына ия булган, торак пункт территориясендә даими яки күбесенчә яшәүче, яшәү урынында теркәлгән гражданнар санының 5 процентын тәшкил итәргә, ләкин 25 тән ким булырга тиеш түгел.

2.4. Имза кәгазьләре имзалар җыюче кешеләр тарафыннан тикшерелә, тикшерү датасы, фамилия, исем, атасының исеме, туган көне, паспорт яки аны алмаштыручы документ сериясе һәм номеры, яшәү урынындагы адресы күрсәтелә һәм җирлек башлыгына җибәрелә.

**Гражданнар җыенын үткәрү турында карар кабул итү тәртибе**

2.5. Инициатив төркем тарафыннан чакырыла торган гражданнар җыены муниципаль берәмлекнең вәкаләтле органы карары белән (2 нче кушымта), ә җирлек башлыгы инициативасы буенча – җирлек башлыгы карары белән (3 нче кушымта) кирәкле документлар килгән көннән соң 30 көн эчендә билгеләнә

2.6.Җирлек башлыгы яки муниципаль берәмлекнең вәкаләтле органы гражданнар җыенын, максатка ярашлы түгел, дип, үткәрүдән баш тартырга тиеш түгел.

2.7. Гражданнар җыенына кертелгән мәсьәлә Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына каршы килергә тиеш түгел. Гражданнар җыены соравы кыска, ягъни аңа бертөрле генә җавап бирергә мөмкин булырлык итеп төзелергә тиеш.

2.8.Гражданнар җыенын билгеләү турындагы карарны рәсми рәвештә бастырып чыгару (халыкка җиткерү) тәртибе, аны күчерү җирлек Уставы тарафыннан билгеләнә һәм муниципаль хокук актларын бастырып чыгару (халыкка җиткерү) өчен җирлек уставында каралган тәртиптә бастырыла.

Гражданнар җыенын үткәрү турындагы җирлек башлыгы яки муниципаль берәмлекнең вәкаләтле органы карарларында гражданнар җыенына кертелә торган сорау, гражданнар җыенын үткәрү вакыты һәм урыны турында мәгълүмат; җыенны оештыручы – муниципаль берәмлек органының структур бүлекчәләре турында мәгълүматлар күрсәтелә.

2.9. Гражданнар җыенына әзерләнү һәм аны үткәрү өчен җаваплы муниципаль берәмлекнең структур бүлекчәсе (башкару-боеру органы) муниципаль берәмлек башлыгының гражданнар җыенын үткәрү турындагы карары нигезендә сайлау хокукына ия торак пункт кешеләренең исемлеген төзи, гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерли; муниципаль берәмлек массакүләм мәгълүмат чараларында һәм гражданнар җыены турында башка ысуллар белән халыкка хәбәр итә (4 нче кушымта).

Җирлек башкарма комитеты гражданнар җыенын үткәрү өчен бина бирергә тиеш.

2.9.1. Торак пункт кешеләренә гражданнар җыенын үткәрү вакыты һәм урыны турында алдан хәбәр ителә. Гражданнар җыенын билгеләү, гражданнар җыенын үткәрү вакыты һәм урыны турындагы карар гражданнар җыенын үткәрү көненә кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча мәҗбүри бастырып чыгарылырга тиеш.

2.9.2. Җыенның һәр катнашучысы гражданнар җыенын үткәрү көненә кадәр 5 көннән дә соңга калмыйча муниципаль берәмлек органының структур бүлекчәсендә гражданнар җыены карарына кертелә торган материаллар белән танышырга, шулай ук аларның күчермәсен алырга хокуклылар

2.10. Гражданнар җыены турындагы Нигезләмә нигезендә гражданнар җыенын үткәрү датасы соңрак срокка күчерелергә мөмкин. Гражданнар җыенын күчерү турындагы карар җыенны үткәрү билгеләнгән датага кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча кабул ителергә тиеш.

## 3. Гражданнар җыенын үткәрү турында

3.1. Җыенга килгән гражданнар җыенда катнашучы кешеләрне теркәү өчен җирлек башлыгы тарафыннан билгеләнгән, җыенда катнашучы, торак пункт кешеләре исемлегенә кертелгән һәм сайлау хокукына ия зат тарафыннан теркәлә. Исемлектә гражданның фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган көне, яшәү урынынагы адресы, паспортының сериясе һәм номеры күрсәтелә.

3.2. Җыенда катнашырга шулай ук хәлиткеч тавыш бирү хокукы булмаган, ләкин җыенда катнашырга теләк белдергән башка гражданнарга, предприятие, учреждение, оешма җитәкчеләренә (әгәр җыенда ткишерелә торган мәсьәләләрне хәл итү алар эшчәнлеге белән бәйләнгән булса), башка массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләренә дә рөхсәт ителә.

3.3. Сайлау хокукына ия булучы торак пункт кешеләре исемлегендә төгәлсезлекләр ачыкланган очракта торак пункт кешесе теркәлә, һәм әлеге муниципаль берәмлек башлыгы аңа җыенда катнашырга рөхсәт бирә.

3.4. Гражданин шәхесен раслаучы (Россия Федерациясе гражданины паспорты, хәрби билеты, чит ил гражданинының паспорты, Россия Федерациясендә яшәүгә рөхсәт, Россия Федерациясендә вакытлыча яшәүгә рөхсәт) документ язмаларның төгәлсезлеген (яки аларның булмавын) раслау булып хезмәт итә.

3.5. Гражданнар җыены анда сайлау хокукына ия булган торак пункт кешеләренең яртысыннан артыгы катнашканда тулы хокуклы була. Кворум булмаганда гражданнар җыенын үткәрүнең яңа датасын муниципаль берәмлек башлыгы билгели. Бу очракта гражданнар җыены гражданнар җыены үткәрү билгеләнгән көннән соң ун көннән дә иртәрәк үткәрелергә тиеш түгел.

3.6. Гражданнар җыенында тавыш бирү ачык яки яшерен була ала. Тавыш бирү формасы турындагы карар гражданнар җыенында кабул ителә.

3.7. Яшерен тавыш биргәндә гражданнар җыенында катнашу өчен теркәлгән гражданинга тавыш бирү өчен бюллетень бирелә ( 5 нче кушымта).

3.8. Гражданнар җыенында җирлек башлыгы яки гражданнар җыенында теркәлгән катнашучылар арасыннан ачык тавыш бирү юлы белән күпчелек тавыш алган башка кеше рәислек итә ала. Рәислек итүче кандидатураларын гражданнар җыенында катнашучылар тәкъдим итә ала.

3.9. Гражданнар җыены сәркатипне һәм хисап комиссиясен сайлый. Хисап палатасы әгъзалары саны ике кешедән артык булырга тиеш түгел. Гражданнар җыенының эш көненә өстәмә сораулар рәислек итүче, җирлек

башлыгы, гражданнар җыенында катнашырга хокуклы гражданнар тарафыннан кертелә ала.

Эш көненә мәҗбүри тәртиптә гражданнар җыенын чакыру инициаторлары керткән сораулар кертелә. Күрсәтелгән сораулар беренче чиратта карала. Гражданнар җыенының эш көненә кертү турындагы карар аның өчен җыенда катнашкан гражданнарның кимендә яртысы тавыш бирсә, кабул ителгән дип санала.

3.10.Гражданнар җыены җыенда рәислек итүче тарафыннан ачыла. Җыенда рәислек итүче гражданнарның җыенын оештыра, тәртипне саклый, хисап комиссиясенең эшенә кураторлык итә, тикшерелә торган мәсьәләләр буенча чыгыш ясау өчен сүз бирә, тавыш бирүнең билгеләнгән тәртибен тәэмин итә (6 нчы кушылма).

3.11. Гражданнар җыенында сәркатип беркетмә алып бара, анда гражданнар җыенын үткәрү көне һәм урыны, сайлау хокукына ия гражданнар саны, катнашучылар саны, көн тәртибе, чыгышларның кыскача эчтәлеге, карала торган сораулар буенча тавыш биргән гражданнар саны күрсәтелә.

3.12. Беркетмә җыенда рәислек итүче зат һәм җыен сәркатибе тарафыннан имзаланып, җирлек башлыгына тапшырыла. Җыенда катнашучылар исемлеге беркетмәгә теркәлә.

## 4. Гражданнар җыенының карарлары

4.1. Гражданнар җыенында катнашучыларның сайлау хокукына ия булган яртысыннан күбрәге тавыш бирсә, җыен карары кабул ителгән дип санала.

4.2. Җыенда кабул ителгән карарлар муниципаль хокук актлары булып торалар, җирлек башлыгы тарафыннан имзаланалар һәм Татарстан Республикасы муниципаль норматив актлар регистрына кертелергә тиешләр (7, 8 нче кушымталар).

4.3. Җирле үзидарә органнары һәм җирле үзидарәнең вазыйфаи затлары гражданнар җыенында җирлек Уставы билгеләгән, алар арасындагы вәкаләтләрне чикләү нигезендә кабул ителгән карарларны үтәүне тәэмин итәләр.

4.4. Җыенда кабул ителгән карар юкка чыгарылырга яки җыенда башка карар кабул итү юлы белән үзгәртелергә, яисә суд тәртибендә гамәлдән чыккан, дип танылырга мөмкин.

4.5. Гражданнар җыенында кабул ителгән карарлар рәсми бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) һәм муниципаль хокукый актлар өчен таләпләр нигезендә рәсмиләштерелергә тиешләр.

4.6. Торак пункт кешеләренең турыдан-туры ихтыярын белдерү юлы белән кабул ителгән карарны гамәлгә ашыру өчен өстәмә рәвештә муниципаль хокук актын кабул итү (бастыру) таләп ителсә, компетенциясенә күрсәтелгән актны кабул итү (бастыру) керә торган җирле үзидарә органы яки вазыйфаи зат гражданнар җыенында кабул ителгән карар үз көченә кергән көннән алып 15 көн эчендә тиешле мунициаль хокук актын әзерләү һәм (яки) кабул итү срогын билгеләргә тиешләр. Күрсәтелгән срок өч айдан арта алмый.

**Гражданнар жыенының карарларын үтәү**

4.7. Җыенда кабул ителгән карарлар торак пункт территориясендә мәҗбүри төстә үтәлергә тиешләр һәм нинди дә булса дәүләт хакимияте органнарының, аларның вазыйфаи затларының яки җирле үзидарә органнарының раславына мохтаҗ түгелләр.

4.8. Җыенда кабул ителгән карарларны үтәмәү закон нигезендә җаваплылыкка тартуга сәбәп булып тора.

**Алексеевск муниципаль районының**
**Лебяжье авыл җирлеге башлыгы,**
**Совет рәисе** **М.Б.Зверев**

СОВЕТ
ЛЕБЯЖИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районының
Лебяжье авыл жирлеге торак пунктларында
гражданнар җыенына әзерләнү һәм аны
үткәрү тәртибе турында”гы Нигезләмәгә
**1 нче кушымта**

ИМЗАЛАР КӘГАЗЕ

Без, аста кул куючылар, гражданнар җыенын үткәрү инициативасын хуплыйбыз

___

гражданнар җыенын үткәрү сроклары
Алексеевск муниципаль районының Лебяжье авыл _____ җирлегендә сорауны тәгъбир итү

| Тәр тип сан ы | Фамилия, исем, атасының исеме | Туу көне | Яшәү урыны адресы | Паспорт яки аны алмаштыручы документ сериясе, номеры | Имза кую датасы | имза |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |

Имзалар кәгазен раслыйм___________________________________________
(фамилия, исем, атасының исеме, туу көне

___________________________________________________________

Имза җыючы кешенең паспорты яки аны алмаштыручы документы сериясе, номеры

____________________ (имза һәм дата)

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районының
Лебяжье авыл җирлеге торак пунктларында
гражданнар җыенына әзерләнү һәм аны
үткәрү тәртибе турында"гы Нигезләмәгә
**2 нче кушымта**

**КАРАР**

**_______ 2018 г.** **№ _____**

**Гражданнар җыенын билгеләү турында_______ Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Лебяжье авыл җирлеге торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча фикер алыштылар**

"Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында"гы 6 октябрь, 2003 ел, 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 нче маддәләре, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында"гы 28 июль, 2004 ел, 45-ЗРТ санлы Татарстан Республикасы законының 35 нче маддәсе һәм **Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Лебяжье авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставының 23 нче маддәсен гамәлгә ашыру максатында**

**Лебяжье авыл җирлеге Советы карар бирде:**

1. Алексеевск муниципаль районының Лебяжье авыл җирлеге торак пунктында 20_____ елның ——— үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына кертелә торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

"Сез 2019 елда гражданнарга Лебяжье авыл җирлеге территориясендә теркәлгән балигъ булган һәр кешегә (үзара салымнан азат ителгән гражданнардан кала) ——— сум күләмендә үзара салым акчасы кертергә һәм алынган акчаны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә ризамы?"

ӘЙЕ ЮК».

3. Әлеге карарны Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрдә, авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземдә калдырам.

Лебяжье авыл җирлеге
башлыгы, Совет рәисе М.Б.Зверев

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районының
Лебяжье авыл җирлеге торак пунктларында
гражданнар җыенына әзерләнү һәм аны
үткәрү тәртибе турында"гы Нигезләмәгә
**3 нче кушымта**

**"Гражданнарның җыенын билгеләү
турында _____
Лебяжье авыл җирлеге
ноктасына кадәр уза
кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча
район башлыгы урынбасары
гражданнарның үзара салым акчасы»**

"Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында"гы 6 октябрь, 2003 ел, 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 нче маддәләре, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында"гы 28 июль, 2004 ел, 45-ЗРТ санлы Татарстан Республикасы законының 35 нче маддәсе һәм Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Лебяжье авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставының 23 нче маддәсен гамәлгә ашыру максатында

**Лебяжье авыл җирлеге Советы карар бирде:**

1. Алексеевск муниципаль районының Лебяжье авыл җирлеге торак пунктында 20____ елның ——— үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә

2. Гражданнар җыенына кертелә торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

"Сез 2019 елда гражданнарга Лебяжье авыл җирлеге территориясендә теркәлгән балигъ булган һәр кешегә (үзара салымнан азат ителгән гражданнардан кала) ——— сум күләмендә үзара салым акчасы кертергә һәм алынган акчаны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә ризамы?"

ӘЙЕ ЮК».

2. Әлеге карарны Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрдә, авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземдә калдырам.

**Лебяжье авыл җирлеге
башлыгы Совет рәисе М.Б.Зверев**

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районының
Лебяжье авыл җирлеге торак пунктларында
гражданнар җыенына әзерләнү һәм аны
үткәрү тәртибе турында"гы Нигезләмәгә
**4 нче кушымта**

# ИСЕМЛЕГЕ

яшәүче ________________________________ ________________________________
(торак пункт исеме) (җирлек исеме)
_____________________________ , сайлау хокукына ия булучылар
(муниципаль район исеме)

| Тәртип саны | Фамилия, исем, атасының исеме | Туу көне | Яшәү урыны адресы | Паспорт яки аны алмаштыручы документ сериясе, номеры | Имза кую датасы | имза |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |

Гражданнар җыенында рәислек итүче _______ _____________________
(имза) (имзаны расшифровкалау)

Гражданнар җыены сәркатибе _______ _____________________
(имза) (имзаны расш ифровкалау)

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районының
Лебяжье авыл җирлеге торак пунктларында
гражданнар җыенына әзерләнү һәм аны
үткәрү тәртибе турында"гы Нигезләмәгә
**5 нче кушымта**

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Лебяжье авыл җирлеге составына керә торган ———— торак пунктта гражданнарның үзара салым акчасын кертү һәм файдалану мәсьәләсе буенча яшерен тавыш бирү

**БЮЛЛЕТЕНЕ**

| | | |
|---|---|---|
| Яшерен тавыш бирүгә куелган сорауның эчтәлеге | «Әйе» | ☐ |
| | «Юк» | ☐ |
| | «Тавыш бирми калам» | ☐ |

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районының
Лебяжье авыл жирлеге торак пунктларында
гражданнар җыенына әзерләнү һәм аны
үткәрү тәртибе турында"гы Нигезләмәгә
**6 нчы кушымта**

# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ БЕРКЕТМӘСЕ

________________________________________

«___» ____________ 20__ ел №_____

________________________________

(торак пункт исеме)

Катнаштылар ________________________________________ чел.

(торак паунктта яшәүче гражданнарның гомуми саны, сайлау хокукына ия гражданнар саны, катнашучылар саны)

Гражданнар җыенында
рәислек итүче ________________________________________

(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

Гражданнар җыены сәркатибе________________________________

(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

**КӨН ТӘРТИБЕ**

1.

2.

**Беренче мәсьәлә буенча тыңладылар:**

________________________________________

(фамилиясе, исеме, атасының исеме)
(чыгышның кыскача эчтәлеге яки чыгыш темасы, теркәлә)

**Чыгыш ясадылар:** 1. ________________________________________

(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

(чыгышның кыскача эчтәлеге яки чыгыш темасы, теркәлә) һ.б.лар (чыгыш ясаучы гражданнар саны буенча)

**КАРАР ИТТЕЛӘР:** (карарның эчтәлеге)

Тавыш бирү нәтиҗәләре: «Әйе" ____ кеше
«Юк» ____ кеше.
«Тавыш бирми калды» ____ кеше

Карар ____________________

Кабул ителде (кабул ителмәде)

**Икенче мәсьәлә буенча тыңладылар:**

________________________________________

(фамилиясе, исеме, атасының исеме)
(чыгышның кыскача эчтәлеге яки чыгыш темасы, теркәлә)

**Чыгыш ясадылар:** 1. ________________________________________

(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

(чыгышның кыскача эчтәлеге яки чыгыш темасы, теркәлә) һ.б.лар (чыыш ясаучы гражданнар саны буенча)

**КАРАР ИТТЕЛӘР:** (карарның эчтәлеге)

Тавыш бирү нәтиҗәләре: “Әйе” ____ кеше
«Юк» ____ кеше.
«Тавыш бирми калды» - ____ кеше

Карар ______________________________
кабул ителде (кабул ителмәде)

| | | |
|---|---|---|
| Гражданнар җыенында рәислек итүче | _________<br>имза | ___________________________<br>(имзаны расшифровкалау) |
| Гражданнар җыены сәркатибе | _________<br>имза | ___________________________<br>(имзаны расшифровкалау) |

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районының
Лебяжье авыл җирлеге торак пунктларында
гражданнар җыенына әзерләнү һәм аны
үткәрү тәртибе турында"гы Нигезләмәгә
**7 нче кушымта**

**КАРАР**

**Татарстан Республикасы**
**Алексеевск муниципаль районының**
**Лебяжье авыл җирлеге составына керүче**
**торак пунктларда———— гражданнар**
**җыены нәтиҗәләре турында**

"Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында"гы Федераль законның 25.1, 56 нче маддәләре, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында"гы Татарстан Республикасы законының 35 нче маддәсе нигезендә 20** елның ————— булган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән "Сез 2019 елда Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Лебяжье авыл җирлеге составына керүче торак пунктта Лебяжье авыл җирлеге территориясендә теркәлгән балигъ булган һәр кешегә (үзара салымнан азат ителгән гражданнардан кала) ——— сум күләмендә үзара салым акчасы кертергә һәм алынган акчаны конкрет юнәлешләргә сарыф итүгә җибәрергә ризамы?" дигән мәсьәлә буенча беркетмә төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә ——— гражданнар җыенында катнашучы, ———тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыены катнашучылары саны кертелде.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар түбәндәгечә бүленде:

"Әйе" позициясе өчен ——— гражданнар җыенында катнашучы, "Юк" позициясе өчен ————— җыенда катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар итте:

1.Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының

Лебяжье авыл җирлеге составына керүче торак пунктта гражданнар җыены үткәрелде, гражданнар җыены нәтиҗәләрен чын дип танырга.

2. "Сез 2019 елда Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Лебяжье авыл җирлеге составына керүче торак пунктта Лебяжье авыл җирлеге территориясендә теркәлгән балигъ булган һәр кешегә (үзара салымнан азат ителгән гражданнардан кала) ——— сум күләмендә үзара салым акчасы кертергә һәм алынган акчаны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә ризамы?" дигән мәсьәлә буенча карарны танырга.

3. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының

Лебяжье авыл җирлеге гражданнары җыены нәтиҗәләрен халыкка җиткерергә ( гражданнар җыены нәтиҗәләрен халыкка җибәрү ысулын күрсәтергә).

Әлеге карарны Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Лебяжье авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокук актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче __________ ____________________
имза (имзаны расшифровкалау)

Гражданнар җыены сәркатибе __________ ____________________
имза (имзаны расшифровкалау)

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районының
Лебяжье авыл җирлеге торак пунктларында
гражданнар җыенына әзерләнү һәм аны
үткәрү тәртибе турында"гы Нигезләмәгә
**8 нче кушымта**

## ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

(торак пунктта ______ Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Лебяжье авыл җирлеге)

«___» ____________ 20__ ел №_____

"Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында"гы Федераль законның 25.1, 56 нче маддәләре, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында"гы Татарстан Республикасы законының 35 нче маддәсе нигезендә

гражданнар җыены————————————— **КАРАР БИРДЕ:**

торак пункт исеме

1.
2.
3.

Гражданнар җыенында рәислек итүче ___________ ______________________

имза (имзаны расшифровкалау)

Лебяжье авыл җирлеге башлыгы, Совет рәисе ___________ ______________________

(имза) (имза расшифровка)